МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.09.2015 г. Казань № под-9280/15

**2015 елда татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләр булдыру турында**

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар планының 3.6.3 пункты нигезендә боерам:

1. Татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләр билгеләргә.
2. Татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы яшь һәм алдынгы галимнәр өчен исемле стипендияләр алуга конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. 2015 елның IV кварталында татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлек алып баручы яшь һәм алдынгы галимнәр өчен исемле стипендияләр алуга конкурс үткәрергә.
4. Татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы яшь һәм алдынгы галимнәр өчен исемле стипендияләр эзләүгә конкурсның эксперт советы составын расларга (2 нче кушымта).
5. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмаларына хезмәткәрләрнең конкурста актив катнашуын тәкъдим итәргә.
6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Поминовка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Премьер-министры урынбасары – министр** **Э.Н. Фаттахов**

**Кушымта № 1**
**Татарстан Республикасы**
**Мәгариф һәм фән министрлыгы**
**боерыгы**
**15.09.2015 ел № под-9280/15**

# НИГЕЗЛӘМӘ
## татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләр алуга конкурс уздыру тәртибе турында

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлек алып баручы яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела һәм «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында тормышка ашырыла.

1.2. Татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлек алып баручы яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләр алу конкурсы турында мәгълүмат (алга таба-Конкурс) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында түбәндәге адрес буенча: http://mon.tatarstan.ru «Чаралар»бүлегендә урнаштырыла.

1.3. Конкурс Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тараыннан уздырыла.

1.4. Конкурсның максаты – татар теле һәм әдәбиятын укыту өлкәсендә фәнни һәм фәнни-педагогик кадрларның сыйфатлы составын яхшырту өчен шартлар тудыру.

Конкурсның бурычлары:

- фәнни-педагогик хезмәткәрләрнең статусын күтәрү һәм социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;
- яшь галимнәр санын арттыру һәм Россия яшьләрен фән һәм мәгариф өлкәсендә беркетүгә ярдәм итү;
- татар телен һәм әдәбиятын укытуда алдынгы тәҗрибәдән файдаланучы фәнни-педагогик кадрлар санын арттыру;
- татар филологиясе өлкәсендә фәнни казанышларны популярлаштыру.

1.5. Исемле стипендияләр бүлеп бирү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

Конкурста җиңүчеләргә бүлеп бирелә:

татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлек алып баручы алдынгы галимнәр өчен 70000 сум күләмендә 10 стипендия;

татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлек алып баручы яшь галимнәр өчен 30000 сум күләмендә 10 стипендия.

## 2. КОНКУРСТА КАТНАШУ ШАРТЛАРЫ

2.1. Конкурста катнашу өчен татар филологиясе өлкәсендә эшләүче югары белем бирү оешмаларының яшь һәм әйдәп баручы галимнәре чакырыла.

2.2. Конкурста катнашу шәхсән.

2.3. Дәгъва кылучыларга карата таләпләр.

2.3.1. Татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлек алып баручы алдынгы галимнәр өчен стипендиягә дәгъва кылучылар соңгы 5 елда түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

- татар телен һәм әдәбиятын укыту өлкәсендә фәнни-педагогик стажы 15 елдан да ким булмаска тиеш (хезмәт кенәгәсенең күчермәсе белән раслана);
- халыкара нәшриятларда бастырылган 1 монографиягә (монография бүлекләре) һәм Россия нәшриятларында бастырылган кимендә 2 монографиягә (монография бүлекләре) (титул битенең күчермәсе кушып бирелә, басманы урнаштыруның электрон адресы күрсәтелә) ия булу;
- мәгълүматның реферирлана торган базаларында кимендә 2 фәнни мәкалә (Россия фәнни цитаталау индексы, Scopus, Wos) һәм югары аттестация комиссиясе киңәш иткән басмаларда 5 фәнни мәкалә булырга тиеш (күчермә кушымта итеп бирелә, басманы урнаштыруның электрон адресы күрсәтелә);
- дөньяда татар телен һәм әдәбиятын популярлаштыру буенча агарту эшчәнлеген алып баручы татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә халыкара фәнни һәм мәгариф проектларында катнашырга;
- татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өлкәсендә дәүләт программа-норматив документларын әзерләүдә катнашырга (документлар исемлеге кушымтада бирелә);
- халыкара, бөтенроссия һәм республика фәнни-белем бирү чараларын, конкурсларны, олимпиадаларны әзерләүдә һәм уздыруда катнашырга (чаралар исемлеге кушымтада бирелә);
- грант проектлары җитәкчесе һәм/яки башкаручы буларак (Россия гуманитар фәнни фонды, Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды, Россия фәнни фонды) (проектлар, урнаштырылган мәгълүмат сайты күрсәтелә);
- ел саен фәнни тикшеренү юнәлеше буенча кимендә 3 халыкара конференция эшендә (доклад) катнашырга.

2.3.2. Татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлек алып баручы яшь галимнәр өчен стипендиягә дәгъва кылучылар соңгы 5 елда түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

- кимендә 5 ел фәнни-педагогик стажга ия булу (хезмәт кенәгәсенең күчермәсе белән раслана);

- мәгълүматның реферирлана торган базаларында кимендә 1 фәнни мәкалә (Россия фәнни цитаталау индексы, Scopus, Wos) һәм югары аттестация комиссиясе киңәш иткән басмаларда 3 фәнни мәкалә булырга тиеш (күчермә кушымта итеп бирелә, басманы урнаштыруның электрон адресы күрсәтелә);

- татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өлкәсендә дәүләт программа-норматив документларын әзерләүдә катнашырга (документлар исемлеге кушымтада бирелә);

- татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә республика фәнни һәм мәгариф проектларында катнашырга (чаралар исемлеге кушымтада бирелә);

- грант проектлары җитәкчесе һәм/яки башкаручы буларак (Россия гуманитар фәнни фонды, Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды, яшь галимнәрнең Россия фәнни фонды) катнашырга (проектларның, урнаштырылган мәгълүмат сайты күрсәтелә).

2.3.3. Конкурста катнашу өчен дәгъвә кылучылар әлеге Нигезләмәнең 2.3.1, 2.3.2. пунктында билгеләнгән документлар белән конкурста катнашучы анкетасын (1 нче кушымта) тапшыралар.

2.4. Конкурс кысаларында түбәндәге документлар каралмыйлар:

- әлеге Нигезләмәнең 2.3.1, 2.3.2 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килми торган анкета-заявкалар.

- конкурста катнашуга гариза бирү срогыннан соңрак кергән эшләр.

## 3. КОНКУРСНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ

3. Конкурс ике этапта үткәрелә:

3.1. I этап.

3.1.1. Конкурсның башлануы, шартлары һәм тәртибе турында мәгълүмат 2015 елның 10 октябренә кадәр Министрлык сайтына урнаштырыла.

3.1.2. Югары белем бирү мәгариф оешмаларында конкурста катнашучылар кандидатураларын билгеләү буенча әзерлек эшләре алып барыла.

3.1.3. Конкурс документларын җыю һәм теркәү Министрлыкта 2015 елның 10 ноябренә кадәр гамәлгә ашырыла.

3.2. II этап.

Конкурска тапшырылган материалларга экспертиза уздыру һәм Конкурста җиңүчеләрне ачыклау 2015 елның 30 ноябренә тикле башкарыла.

Эксперт советы составы Министрлык боерыгы белән раслана.

Эксперт советы әйдәп баручы 5 филологтан: татар тел белеме һәм әдәбият белеме өлкәсендә әйдәп баручы, кимендә 15 ел фәнни-педагогик стажга ия филология фәннәре докторларыннан һәм кандидатларыннан тора.

Конкурска тапшырылган эшләр экспертизасы эксперт советы утырышында әлеге Нигезләмәнең 2.3 п. билгеләнгән таләпләргә туры китереп тапшырылган документларны тикшерү юлы белән уздырыла. Утырыш Эксперт советының барлык әгъзалары булу шарты белән хокуклы дип санала.

Экспертиза нәтиҗәләре нигезендә әйдәп баручы галимнәр һәм яшь галимнәр арасында дәгъвә кылучылар рейтингы формалаша. Иң алдынгы галимнәр һәм яшь галимнәр рейтингында беренче 10 юлны алган дәгъвачылар Конкурста җиңүчеләр дип танылa.

Эш нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул эксперт советының барлык әгъзалары тарафыннан имзалана, һәм Министрлыкка конкурсның икенче этабы тәмамланганчы ике эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Эксперт советы карары Министрлык боерыгы белән раслана. Конкурс нәтиҗәләре ахыргы булып тора, яңадан каралмый, суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

3.3. III этап – бүләкләү

3.3.1. Конкурс җиңүчеләре стипендияләр һәм дипломнар белән 2015 елның 25 декабренә кадәр бүләкләнә.

3.3.2. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министерлык сайтына http://mon.tatarstan.ru. адресы буенча 2015 елның 25 декабренә кадәр урнаштырыла..

## 4. ФИНАНСЛАУ

4.1. Конкурсны оештыруга бәйле чаралар «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**Кушымта № 1**

**АНКЕТА**
**татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек алып баручы яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендиягә дәгъва кылучылар исемлеге**

Теркәлү датасы: _____________ Гариза номеры: ________________

1.Мөрәҗәгать итүче ф.и. о..
2. Элемтә өчен мәгълүмат (телефон (ы), e-mail).
3. Туган көне.
4. Гыйльми дәрәҗәсе һәм исеме.
5. Төп эш урыны (оешманың исеме, ведомство, шәһәр, биләгән вазыйфасы).
6. Фәнни-педагогик стажы (хезмәт кенәгәсенең күчермәсе раслана).
4. Резюме соискателя (артык түгел 1 чара).
5. Басманың электрон адресы күрсәтелгән мәкаләләр исемлеге (Нигезләмәнең 2.3 пункты нигезендә һәм эшләрнең күчермәләре белән расланган).
6. Татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә халыкара фәнни һәм белем бирү проектлары исемлеге (тәкъдим итү формасы ирекле).
7. Татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өлкәсендә дәүләт программа-норматив документлары исемлеге (тәкъдим итү формасы ирекле).
8. Дәгъва кылучы катнашкан халыкара, бөтенроссия һәм Республика фәнни-белем бирү чаралары, конкурслар, олимпиадалар исемлеге (тәкъдим итү формасы ирекле).
9. Грант проектлары исемлеге (Россия гуманитар фонды, Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды, Россия фәнни фонды), аларда җитәкче һәм/яки башкаручы сыйфатында катнашучы (яки катнаша).
10. Фәнни тикшеренүләр юнәлеше буенча халыкара конференцияләрдә турыдан-туры докладлар Исемлеге.
11. Өстәмә мәгълүмат.
11.1. Татар филологиясе буенча диссертация советларында әгъза
11.2. Татар филологиясе өлкәсендә халыкара дәрәҗәдәге фәнни вакытлы басмаларны әзерләүдә һәм бастыруда катнашу (документ, басмаларның күчермәләре белән раслана).
11.3. Диссертация тикшеренүенең темасы һәм соңгы 5 ел эчендә публикацияләр исемлеге.
12. Имза соискателя.
13. Документларның күчермәләре.

**Кушымта № 2**
**Татарстан Республикасы**
**Мәгариф һәм фән министрлыгы**
**боерыгы**
**15.09.2015 ел № под-9280/15**

**Татар теле һәм әдәбияты буенча югары квалификацияле кадрлар әзерләү юнәлешендә фәнни-педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләр алуга конкурсның эксперт советы составы**

1. Тарасова Фәнүзә Харис кызы, филология фәннәре докторы, Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегенең тел һәм мәдәниятара коммуникацияләр кафедрасы мөдире, председатель.
2. Кадыйрова Энҗе Хәнәфи кызы, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Габдулла Тукай исемендәге татар тел белеме бүлегенең татар тел белеме кафедрасы доценты.
3. Хадыева Гөлфия Камил кызы, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Габдулла Тукай исемендәге татар тел белеме бүлегенең татар тел белеме кафедрасы доценты.
4. Гәйнуллина Гөлфия Расил кызы, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Габдулла Тукай исемендәге татар тел белеме бүлегенең татар тел белеме кафедрасы доценты.
5. Болгарова Рәмзия Марс кызы, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Габдулла Тукай исемендәге татар тел белеме бүлегенең татар тел белеме кафедрасы доценты.